СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

11 июнь, 1997ел. ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 63 (8075) | Бәясе билгеләнгәнчә

## ЯМЬЛЕ ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ ҮТТЕ - ДӘРТЛЕ ХЕЗМӘТ ДӘВАМ ИТӘ

# ГӨРЛӘП ҮТТЕ САБАН ТУЙЛАРЫ



## Бәйрәм кунак белән ямьле

Шимбә көнне традицион сабантуйга җыелган һәркем көннең аяз, матур булуын тели иде. Шулай килеп чыкты да. Кояш тиз арада күктә җыелып килгән болытларны куып таратты һәм мәйдан ямьле нурларга күмелде. Мондый матурлыкны мәйдан моңарчы күрмәгән иде әле.

Әллә кайдан үзенә тартып тора торган сәүдә палаткалары, балалар аттракционнары паркы, төрле төстәге шарлар, флажоклардан гирляндалар, күптөрле башка декоратив элементлар, иртәнге концерт онытылмас композиция тудырдылар. Бәйрәм символикасы шул иртәдә яңа Норлат аэровокзалын ачу белән дә тулыланды. Анда төп мәртәбәле кунаклар Татарстан Республикасы Премьер - Министры Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин, беренче вице - премьер Равил Фатыйх улы Моратов һәм республика аэрокомпаниясе җитәкчеләре иделәр. Очу полосасына аяк басуга, Премьер - министр «Заманча аэропорт һәм яңа очу полосасы башкалабыз һәм Норлат арасын бермә - бер якынайтты», дип билгеләде. Хәер, анысына район халкы инанырга өлгергән иде инде. Октябрь җире үз депутатын һәм якташын чигүле сөлгеләрдә ипи - тоз, чәчәкләр, шаян такмаклар белән каршы алды, кунаклар баянның күңелле тавышы астында бөтерелгән кызлар биюенә кушылмый кала алмадылар! Менә инде истәлекле тасма киселде, аның алсу - ал кисәген Фәрит Хәйруллович пиджагына беркетеп куйды, тынлы оркестр сәламлау маршын уйнады, бары 7 ай эчендә күтәрелгән аэровокзал бинасы бүлмәләре каралды һәм бәйрәм төркеме төп мәйданга күчте. Менә күчмә эстрада сәхнәсендә район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы, ТР Дәүләт Советы депутаты Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллин халык бәйрәме ачылуын игълан итте. Хакимебез үзенең кыска чыгышында игенчеләребезнең республикада беренчеләрдән булып кыр эшләрен кыска срокта һәм сыйфатлы башкарып чыгуларын ел башыннан халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрергә булышачак, районда әйбәт авыл хуҗалыгы һәм промышленность потенциалы саклануын, нык һәм тотрыклы социаль инфраструктура формалашуын билгеләп үтте. Билгеләнгән һәм реаль максатларга ирешү өчен бердәм хезмәт кирәк.

Ф.Х.Мөхәммәтшин да үз сайлаучыларына сабан бәйрәме уңаеннан эчкерсез теләкләрен җиткерде. Октябрьлеләрдә хезмәткә һәм аның нәтиҗәләренә карата импульс көннән - көн ныграк сизелә, диде ул. Бу күренеш республика җитәкчелеген дә, Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевны да шатландыра, ә октябрьлеләрне яңа җиңүләргә рухландыра, диде ул.

Берничә минуттан һавада милли әләм дулкынланды. Аны күтәрү хокукы «Агрохимсервис» АҖсенең иң яхшы механизаторы Александр Петрович Убамзаров һәм «Кондырча» КХАсы савучысы Сания Вәлиәхмәт кызы Ибәтуллинага тапшырылган иде. Бәйрәм башланды! Яшел мәйданда шәһәрнең эре предприятиеләре, крестьян һәм кооператив хуҗалыклары, профессиональ артистлар, үзешчән сәнгать осталары, яшь спортчылар катнашында театрлаштырылган тамаша башланды. Халык төркеме чолгап алган импровизацияләнгән зур сәхнә аша игенче, икмәк пешерүче, терлекче хезмәтен, кояшлы көнбагыш кырын, «Шалкан» рус әкиятеннән өзек күрсәткән җанлы картиналар үтте. Программаны җыр - бию, спорт композицияләре тулыландырды, аның ахырына Россия Федерациясенең халык артисткасы Лима Кустабаева җитәкчелегендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артистлары чыгышы кушылды. Болын бу минутларда күпмилләтле Татарстанда яшәүче барлык халыклар көйләреннән һәм костюмнарыннан чәчәк атты. Аннан соң да ансамбль артистлары һәм башка башкала профессионаллары тамашачыларны осталыклары белән куандырдылар. Талантлы Венера Ганиева, Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев, Айдар Фәйзерахманов, Равил Шәрәфиев һәм башка артистлар бу көнне былбыл булып сайрадылар. Тамашачылар аларга алкышлар һәм чәчәкләр бүләк иттеләр, ә җавап итеп янә бию, янә җыр, янә тамаша дәвам итте...

**Т.НАЗАРОВА.**



## Бәйге күрке - юртак ат

Ат чабышларының тәмен белгән кешегә быелгы сабантуйда җан рәхәте алырдай мизгелләр җитәрлек булды. Бәйгегә районның егермеләп хуҗалыгыннан, шулай ук «Зүзәйнефть» промыселыннан, мәгариф бүлегеннән, күрше Аксубай районының «Сөлчә» хуҗалыгыннан, юллар идарәсеннән, Самара өлкәсенең берничә хуҗалыгыннан 130дан артыграк ат чыгарылды. Шул исәптән дистәләп ат аерым кешеләрнеке, аерым алганда өч чаптар һәм бер юртак район хакимиятенеке һәм шәхсән хакимият башлыгыныкы иде. Алгарак китеп булса да әйтик, соңгыларының кайберләре узган елгы көзге сабантуйда таң калдырганга күрә, алар быел да игътибар үзәгендә булды. Ярышка иң күп ат гадәттәгечә Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге, Синдряков исемендәге, «Дуслык», «Кондырча», «Рассвет», «Таң», «Правда»(нефтебаза) хуҗалыкларыннан катнашты. Әмма, бер булсын - берәйгәйле булсын дигән әйтемне раслагандай, бәйге хикмәт атларның күплегендә генә түгел икәнлеген ачык күрсәтте, ягъни бер - ике ат белән килеп тә танылып китүчеләр булды.

Яшь чаптарлар узышында беренчелек быел Мичурин исемендәге хуҗалык атларында булыр төсле иде, шуны раслагандай, алардан иң беренче төркемдә чапкан «Ментор» (җайдагы Е.Максимова) үзеннән соң килгән аттан 2 секундка җитезрәк булып чыкты. Әмма иң йөгерекләре икенче төркемдә булган икән шул. Н.Романованың «Секторы» авылдашының нәтиҗәсен 4 секундка яхшыртты, шулай да хуҗалыкка төп призны яулап бирә алмады - «Дуслык»тан «Гульба» финиш сызыгын бер башка алданрак узды. «Рассвет»тан «Буян» өченче нәтиҗә күрсәтте. Аның каравы, мичуринлылар «Сокол»ы (җайдагы В.Яманов) яшь юртаклар ярышында беренчелекне алды, ә «Дуслык»тан «Выпуск» аңардан бер секундка калышып икенче булды.

Биш төркемгә бүленгән карт чаптарлар узышында һәр төркемнең бизәге булырдай атлар шактый иде. Беренче булып старт алганнардан «Ипатия» (Хафизов исемендәге КХА) һәм «Малыш» (Кузнецов исем.) старттан финишкача бер - берсеннән калышмыйча чаптылар һәм нәтиҗәләре арасындагы аерма да ике генә секунд чыкты. Шулай да иң югары нәтиҗәләр икенче һәм өченче төркем атлары арасында булды. Икенче старттан хакимият башлыгының «Олеандр»ы (җайдагы М.Капушев) башта ук алга чыкты, «Дуслык»тан «Седон» (М.Җаббаров) беренче әйләнештә аның эзенә үк диярлек басып килде. Кайсының чыдамрак икәнлеге финиш кисемтәсендә генә ачыкланды: беренчесе 3 минут та 19 секунд нәтиҗә күрсәтте, икенчесе аннан дүрт секундка калышты. Алар икесе дә саф токым атлар икәнлеген искәрсәк, көрәшнең иң мавыктыргычы өченче төркемдә булды. Хакимият башлыгының «Альби», «Дуслык»ның «Гатал» кебек саф токым атлары белән сөт - май комбинатының җирле токым «Артур»ы беренче әйләнештә чабышның башында бардылар. Шулай да икенче әйләнештә «Альби» үз сүзен әйтте - 3200 метрны «Олеандр»га караганда да 3 секундка тизрәк вакытта узды. Теге ике ат шул тәртиптә 3-24 һәм 3-36 нәтиҗә күрсәттеләр. Шулай итеп җирле токым атлар арасында «Артур»га тиңнәр булмады, «40 лет Победы»дан «Графит» икенче, алда телгә алынган «Ипатия» өченче урыннарга чыктылар.

Карт юртаклар чабышында беренчелек өчен көрәш аеруча кискен булды. Былтыргы чемпион «Обер»ның («Рассвет») хакимиятнең «Резонас» атыннан бер адым да калмыйча диярлек чабуы гаҗәп түгел иде, әмма финиш сызыгын узганда көрәшне секундның уннан бер өлешләре хәл итте - тезгене Йосыф Әхмәтсафин кулындагы икенче ат барыбер җитезрәк булды.

(Дәвамы 2 нче биттә).

### Номерга телеграмма

## КАДЕРЛЕ ЧЫГАРЫЛЫШ КЛАСС УКУЧЫЛАРЫ!

***Бер акыл иясе әйткән: безнең тормышыбызны даими, ә суы һәр мизгел саен яңарып тора торган елгага ошарга тиеш. Сезнең тормышыгызда зур истәлекле вакыйга булды: сез мәктәпне тәмамладыгыз. Сезне бу тормышыгыздагы җитди вакыйгага уңаеннан кайнар котлыйм. Җәмгыять үзенә алмаш, сезне катлаулы бурычлар көтә. Бу бурычлар шулкадәр җаваплы, шулкадәр зур. Сезнең укытучыларыгыз, ата - аналарыгыз сезне Россияне күтәрерсез дип ышаналар. Бу өметкә лаеклы булыгыз! Хәзер якты фикерле, булдыклы куллы, кайнар йөрәкле кешеләр кирәк. Сез бу сыйфатларның барысын да мәктәптә алдыгыз дип ышанам. Сезнең тормышыгыз югарыда телгә алынган суы һәрвакыт яңарып торган йөгерек елгага ошасын. Хәерле юлга, кадерле якташларым!***

**Сезгә ихтирам белән Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутаты А.К.ХАМАЕВ.**

## Яшен генә димәссең...

5 нче июньдә төнлә яшьнәгән җәйге яшен эзсез үтмәде. Яшен атудан Якушкино авылында такта ярдыру цехы һәм цемент саклау бинасы янды, Абрыскино авылында ике хуҗалыкта йорт яны корылмалары зыян күрде.

### Җир турында сөйләшәбез

# «Алмалык»ны гөлбакча итик

«Норлатнефть» НГДУсының «Алмалык» бакчачылык ширкәтенең оешуына быел алты ел тулды. 44 гектар мәйданы, 630 җир участогы булган бу ширкәт районыбызда да иң зурысы булып санала. Исәпләп караганда, 630 бакча хуҗасы янына барчасының да гаиләләрен кушсаң зур гына авыл килеп чыга бит. Шуңа күрәдер, аның мәшәкатьләре дә кечкенә түгел. Әле участоклар бүленгәндә генә җирләрнең 40 проценты чәчәргә яраксыз - саланчак (аксыл туфраклы) яки дымлы түбәнлектә урнашкан иде. Яз көннәрендә туфракның өлгереп җитә алмавы сәбәпле, бары тик май ахырында гына чәчәргә мөмкинлек туа иде. Ә инде көз яңгырлырак килсә, түбәнчелектә урнашкан участоклар су астында калып, юллар кереп булмаслык хәлгә килә иде. Шушы җирләргә кайбер хуҗалар үз көче белән, кайберәүләр оешма ярдәме белән күп кенә җир китерделәр. Юлларга да таш ташылды, ком түшәлде. Дөрес, аларны тиешле дәрәҗәгә китерү ширкәт хәленнән генә килә торган эш түгел. Бакчачылыкта җирләрнең якынча 90 проценты нефтьчеләрнеке, шуңа да НГДУның төрле цех һәм участок җитәкчеләренә үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә туры килә. Үз эшчеләренә мөнәсәбәтләрен суытмыйча, аларның мәнфәгатьләренә карата кызыксынучанлык күрсәтсеннәр иде җитәкчеләр.

Бакчачылыкта һәр участок хуҗасының битедер ул, мөгаен: кемнеңдер бакчасы чәчәк түтәледәй чиста, матур, ә кемнекендер чүп үләннәре баскан. Әмма шунысы бар, бакчачылык күмәк оешма булгач, бакча чүпләреннән арынмасаң, тирә - күршеңнекенә зыян килә, ул чүп үләннәре бөтен бакчачылыкка тарала. Шуңа да хуҗаларга мөрәҗәгать итеп, җирләрегезне чиста тотыгыз, җыелган чүпләрегезне юлга түгел, ә үз бакчагыз кырыена чокыр казып шунда күмә барыгыз. Ул үзегезгә киләсе ел өчен әзер черемә булып хезмәт итәчәк. Ә юлга ташланган чүпләрнең орлыклары җил белән кире үзегезгә кайтыр яки яңгырдан соң юлларны сазга әйләндерәчәк.

Кайбер үсентеләрне утырту үзенчәлекләре хакында да онытырга ярамый. Мәсәлән, кура җиләге, карлыган куаклары күршегезнең бакчасы белән чиктән бер метр ераклыкта булырга тиеш. Кура җиләген юл кырыена утырту дөресрәк, шулай иткәндә ул күршегезнең җиренә таралмаячак.

Биредә бер, ике ел дәвамында җирләре ташландык хәлдә торган участоклар да бар. Бүгенге көндә алар 7әү. Кисәтеп шуны әйтәсе килә, мондый бакчаларның хуҗалары районның җир ресурслары комитеты карары буенча административ җаваплылыкка тартылачаклар. Ә инде бу участоклар ике ел шундый хәлдә торган очракта, алар идарә утырышында каралып, ширкәт уставы таләбе буенча чиратта торган башка хуҗаларга тапшырылачак.


Ә инде тормышта килеп чыккан объектив сәбәпләр аркасында бакча каралмаса, гариза нигезендә аның хуҗасы штрафтан азат ителәчәк.

1993 елда һәр бакча хуҗасына вакытлы таныклык бирелгән иде. 1995 елның гыйнварендә алар үз көчен югалтты. Хәзерге вакытта ел саен взнослар түләп барган хуҗаларга җиргә дәүләт акты биреләчәк. Анда әйтелгәнчә, сезнең участок һәм аның тирәсеннән үткән юл әлеге хуҗа карамагына тапшырыла. Ә инде взнос түләмәгәннәр өчен бакчачылык җәмгыяте ул участок өчен салым түләмәячәк, шунлыктан салым инспекциясендә аңа пеня үсеп барачак. Мисал өчен 1996 елда 1 сутый җир өчен 3000 сум түләргә булса, 1997 елда ул 6000 сум тәшкил итәчәк.

Ширкәт гомуми хуҗалык булгач, һәрнәрсәне як - ягыңа каранып эшләргә туры килә. Әмма моны истә тотмыйча аңа җавапсыз караучылар да шактый әле. Җәяүлеләр, велосипедлыларга уңай булсын өчен, берничә җирдә махсус кечкенә ишекләр ясаткан идек. Ләкин кайберәүләр аннан чыкмыйча, тимер сеткалардан ясалган коймаларны ертып шуннан йөриләр. Шул тишекләрдән терлек - туар кереп, койма җимерелер дип уйлап та карамыйлар булса кирәк. Җиңел транспорт белән килүчеләрнең дә ял итүче яки эшләүчеләргә комачаулау очраклары бар.

НГДУның УТТсында йөк машиналарын йөртүче 120ләп бакча хуҗасына аерым кагылып үтмичә булмый. Бакча эчендәге юлларыбызның аяныч хәле аларның «тырышлыгы» нәтиҗәседер, дисәм һич тә ялгыш булмас. Ул юллар барыбызныкы да, алар өчен һәммәбез дә салым түлибез, шуңа күрә, әйдәгез бер - беребезне хөрмәт итик. Кирәксә - кирәкмәсә дә юлларны бозып эчкә үтеп керүнең хаҗәте юк.

Шундый зур коллективта эшләгәндә төрле имеш - мимешләр, аңлашылмаучанлыклар да килеп чыгуы гаҗәп түгел. Аларның иң зәһәре акча мәсьәләседер, мөгаен. Бакчачылыгыбыз оешкан елларда ук халыктан смета буенча исәпләп, коймалар, су торбалары сатып алырга дип акча җыйган идек. Хәтерегездәдер, ул чордагы инфляция агымына эләгеп ул акчалар тулысынча юкка чыкты. Шуңа күрә яңа бәяләрне күздә тотып, яңадан акча җыярга туры килде. Шуларга, күргәнегезчә, бакча тирәсен 3 см. озынлыгындагы тимер челтәрле койма белән тоттык, аннары «Алмалык»тан 4 км. ераклыкта узган су магистраленә тоташтыру белән шөгыльләндек. Участоклар арасына задвижкалар куеп чыктык. Әгәр дә нефтьчеләр үз мәрхәмәтләреннән ташламаса, без дә бәлки сулы булырбыз дип ышанабыз.



Соңында шуны искәртеп әйтәсе килә: «Алмалык» шәһәребезнең йөзе булып аңа керә торган җирдә урнашкан. Ерак юлдан кайтып керсәң дә, чыгып китсәң дә иң элек аңа күз ташлыйбыз. Әйдәгез, үз өстебезгә, җаваплылыгыбызга алган җирне хөрмәтлик, аны гөлбакча итик, матур, күркәм өйләр салыйк. Аңа күз аткан саен горурланырлык булсын иде.

**Г.ЗАРИПОВ,**
**«Алмалык»ның бакчачылык ширкәте рәисе.**

* * *

***Безнең комментарий:** Г.Зарипов күтәргән мәсьәлә, һичшиксез, актуаль. Бу хакта без дә газетабызда берничә тапкыр сүз кузгаттык. Шәһәр тирәсендәге бакчаларда тәртипсезлекләр битараф булмаган һәркемне борчымый калмый торгандыр, мөгаен. Дөрес, алда сөйләнгән «Алмалык» бакчачылык ширкәте, безнең карашка, шәһәрнең башка ширкәтләре белән чагыштырганда әйбәтрәк хәлдә исәпләнә. Моңа хуҗалар - нефтьчеләрнең хәллерәк булуы, ә бәлки ширкәт өчен чын күңелдән борчылып йөрүче кешесе булуы сәбәпчедер. Ә менә ширкәтләрнең күпчелеге бөтенләй язмыш кочагына ташланган: тирә - яклары тотылмаган, яңгыр яуса кереп булмый, авыл көтүләре, аерым терлекләр дә шунда еш «кунак» булалар. Сүзнең асылы шунда ки, һәр хәлдә тотып алу гына җаваплы предприятиеләр хәленнән килә торган эш, ә аерым хуҗалар бу мәсьәләдә көчсез. Ә бит дәүләт сәясәте, районыбызның тоткан юнәлеше дә шул: халыкны җиргә якынайту, төгәлрәге, җирне рациональ файдаланып, продукцияне үзләренә дә, базар өчен дә җитештерүләре өчен уңай шартлар тудыру. Димәк, үз хезмәте белән гади кешенең дә социаль хәленә җиңеллек китерү күздә тотыла, дигән сүз. Предприятие, оешма җитәкчеләре бу мөһим мәсьәләгә төптәнрәк уйлап карасалар, һичшиксез ширкәтләрдә тәртип артыр һәм проблеманың кискенлеге дә кими төшәр иде.*



## *Илдәниләр бар?*

### Эчик әле, чукынып китсен...



Татарстанның исерткеч эчемлек чыгара торган 5 предприятиесенә аракы белән күпләп сәүдә итәргә хокук бирә торган лицензия вакыты озайтылды. Болар - «Профит - мед» (Казан), «Камское» ачык типтагы акционерлык җәмгыяте (Чаллы), «Биектау Сельхозтехникасы» акционерлык җәмгыяте, Сафиуллинның «Алинә» шәхси предприятиесе (Азнакай), «Петров агрокомплексы» акционерлык җәмгыяте (Сарман).

Ә Казандагы җаваплылыгы чикләнгән «Смуфорси» җәмгыяте һәм ябык типтагы «Арча» акционерлык җәмгыятенең андый лицензияләре гамәлдән алынды.

### Ертык акчага хафаланмагыз




Соңгы вакытта транспорттамы, кибеттәме ертык акчаларны алмый башладылар. Моның өчен бер дә хафаланырга кирәкмәс. Әгәр акчаларыгыз яртылаш кына ертылган булса, банкта алмаштырырга мөмкин. Хәбәрләшү өчен Милли банкның телефоны: 36 - 06 - 20.

# ТӨРЛӘП ҮТТЕ САБАН ТУЙЛАРЫ

## Көчең булса җиңәсең

**( Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Әкият персонажларын шәһәр ягулык белән тәэмин итү предприятиесе ясады. Ә аларны урнаштыру, эскәмияләр ясау, гомумән сабан туе мәйданын бизәүдә төп эш районның күптармаклы производство предприятиесе җилкәсенә төште. Уеннар, ярышларны оештыруда район авыл хуҗалыгы идарәсе, спорт һәм физкультура комитеты, район мәгариф бүлеге, һәм иң мөһиме, республикабызның танылган, көчле артистларын күрсәтеп куандырган район хакимиятенә район халкы рәхмәтнең иң зурысын җиткерәбез.



**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## Менә ул, хуш исле икмәк...

Мәйданның көньяк өлешендә Октябрь райпосы предприятиеләре һәм ОРСлары сәүдә палаткалары ярминкәдәй җәелгән иде. Пешекче һәм кондитерларның оста куллары сабан туе кунаклары өчен ниләр генә әзерләмәгән иде. Тәмле шашлык исе авызларга су китерде, кабарган коймаклар тау булып өелде, үләннәр кушып кайнатылган чәйләрдән пар күтәрелде... Тик шунда ук һәр өстәлдә бәйрәм өстәленең иң түрендә бодай башагының җылысын үз эченә алгандай алтынсу төсле, кетердәп торган тышлы икмәк утыра иде. Икмәк заводы һәм НГДУның «Дока - икмәк» коллективлары бу җәһәттән зур тырышлык күрсәттеләр. Хәер, һәркайсын атап китү дә урынлы булыр иде, шуңа күрә сәүдә ярминкәсе йомгакларын билгеләү белән шөгыльләнүче комиссиягә җиңел булмады. Шулай да сәүдә хезмәткәрләренең күләмле, җитди хезмәтенә алар иң югары бәяне бирделәр:

- Һәммәсе дә мактауга лаек. Әзерлекнең югары дәрәҗәдә булуына һәм товарларның таләп ителгән тәртип буенча куелуына, иң мөһиме фантазия байлыгына куандык. Аеруча «Норлатнефть» НГДУсы, тимер юл, урман хуҗалыгы ОРСларыннан милли киемнәр символиканы куллану-лары уңышлы чыккан: махсус костюмнар, баш киемнәре, бизәкле сөлгеләр белән бизәлгән лотоклар, Республика Дәүләт байрагына тиңдәшле төсләр. Шундый элементлар байтак иде. Ассортимент та ярлы булмады. Кияү пилмәне дисеңме, азык комбинаты квасымы, МПП ресторанында кыслалармы... Санап та бетерергә юк... Шуларга якты йөз, игътибарлы хезмәт күрсәтү дә кушылды.

Призлы урыннар түбәндәгечә бүленде: беренчене райпо һәм НГДУ ОРСы коллективлары алса, икенчене тимер юлы ОРСы, өченчене урман хуҗалыгы ОРСы яуладылар.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

# Мәдәният. Әхлак. Әдәбият.

## КИТАП БЕЛӘН НИ ТИҢЛӘШСЕН?!



**Кычытканлы авылыннан Дания Рамазановна Мансурова районда иң яхшы китапханәче булып танылды. Аның белән безнең корреспондент Т.Назарова әңгәмә корды.**

***- Дания Рамазановна, сезгә котлауларыбызны җиткереп, бернichә сорау бирик әле. Хезмәтегездә нинди сыйфатларны төп билгеләүчеләр дип саныйсыз сез?***

- Хезмәтне хөрмәтләү мөһим, әлбәттә, үз эшеңне биш бармагыңдай белү кирәк.

***- Сез китаплар белән 1971 елдан бирле эшлисез, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исемегез бар. Хәтерегез күпме әсәрне һәм авторның исемнәрен саклый соң? Яраткан китапларыгыз бармы?***

- Әйе, алар Габулла Тукай һәм Сергей Есенин шигырьләре.

***- Авыл китапханәчесе нинди була ул?***

- Ул китаплар саклаучы гына түгел, әлбәттә. Иң элек белем дәрәҗәң югары булырга тиеш. Без халыкка мәдәният очкыннарын гына җиткереп калмыйча, һәркем өчен дә үрнәк булырга да тиешбез. Бу җиңел түгел, әмма зур әһәмияткә ия.

***- Ничек уйлыйсыз, безнең тормышта әдәбиятның роле нинди? Сезнең күзәтүләрегез буенча аңа карата кызыксыну сүнмәдеме? Хәзер бит икътисадый, социаль проблемаларның иге - чиге юк.***

- Китапны алмаштырырдай берни дә юк әлегә. Кино да, телевидение, радио һәммәсе дә аның белән тиңләшә алмый. Китап - мәңгелек. Безнең китапханәдә беркайчан да күңелсез, буш булмый, халык китапка гына түгел, яңа килгән матбугат белән танышырга, фикерләр алышырга да, киңәшкә, консультациягә киләләр. Балалар да, олылар да. Клуб хезмәткәрләре, педагоглар белән без күп төрле чаралар - кичәләр, диспутлар, хезмәт ветераннары, производство алдынгылары, педагоглар белән очрашулар үткәрәбез. Ассоциация җитәкчелеге, җирле үзидарә Советы белән нык бәйләнештә эшлибез.

***- Сез беренче укучыларыгызны хәтерлисезме?***

- Мин үзем Минзәлә районыннан, Кычытканлыга училищены тәмамлап бер ел эшләгәч килдем. Ул чакта фермаларга, остаханәләргә, җәйге лагерьларга еш йөри идем. Шуңа да иң беренче укучыларым арасында сыер савучылар Зәкия Исмәгыйлева һәм Тәнзилә Нуруллинаны атап үтәсем килә.

***- Хезмәтегездән тыш тагын ниләр белән мавыгасыз?***

- Мин җырларга яратам. Бусы бер. Ә тагын гадәти авыл хезмәте - печән чабу яраткан шөгылем. Миңа Кычытканлы ошый. Ул үзе матур, табигате күркәм, халкы да хезмәт сөючән, игелекле. Миңа калса, башка җирдә яшәве кыенгарак туры килер иде.

### Басылганга кире кайтып

## «Норлатча ЧП»

«... Бу вакыйгада гаеплеләргә бары 12шәр яшь, димәк, алар гамәле өчен ата - аналарына җавап бирергә туры киләчәк», - «Дуслык» газетасының май саннарының берсендә басылган 1 нче мәктәпнең 37 укучысы борычлы газ белән агулануы турындагы мәкалә шулай тәмамланган иде.

Тикшерү нәтиҗәләрендә шул ачыкланды: икенче мәктәп укучысы О.Будяшкин әнисе тарафыннан сатып алынган һәм теләсә кем кулына эләгерлек урында сакланган баллонны үз белдеге белән ала. Бу закон тарафыннан хулиганлык, ягъни җәмәгать тәртибен тупас бозу буларак бәяләнә. Әмма, билгеле булганча, ул әле җинаять җаваплылыгына тартылыр яшькә җитмәгән, шуна да ана карата җинаять җаваплылыгы кузгатылмый.

Әмма бу хәл җавапсыз да калдырылмый. Вакыйганың мораль ягын исәпкә алмаганда да (ата - аналарга һәм укытучыларга күпме күнелсез кичерешләр китерде бит ул) хәлнең матди зыян ягы да бар иде бит әле. Анысын территориаль шифаханә кассасы йөзендә район үзәк шифаханәсе кичерде. Бу зыян кайтарылырга да тиеш иде. Шуңа да район прокуратурасы тарафыннан Олег Будяшкинның ата - анасына тотылган зыянны түләү буенча дәгъва куелды. Халык суды бу эшне караганнан соң Будяшкиннардан 1 миллион 611 мең 906 сум түләтергә дигән карар чыгарды. Бөтен республикага таралган Норлатча ЧП шулай тәмамланды. Соңгысы булсын иде ул.

**Ф.ГАЛИМОВА,**
**халык судьясы.**
**Д.ТӘМАЕВА.**

### *Илһамия НИЗАМЕТДИНОВА*

***

Әллә төне бүген шомлы,
Әллә куркаммы үзем?
Зәңгәр күктә йөзгән айда,
Йолдызларда гел күзем.
Якты янган йолдызлардан
Җиргә иңә алсу нур.
Әрәмәлек буйларында
Очрар микән кабат ул?
Күңел, ашкынасың нигә,
Ул барыбер юк инде.
Юаткандай ай яктысы
Минем күңелгә инде.

### *Дустыма*

Кошлар булып очты үсмер чак дип,
Кадалмасын уклар йөрәккә.
Кешеләргә нык ышаныч сакла -
Шул җитми бит кайчак бигрәк тә.
Авыр болыт бер таралмый булмас,
Кояш сибәр җылы нурларын.
Вакытлыча тормыш сынавыннан
Төшмәсеннәр түбән кулларың.

### *Хуҗабикәләргә*

## Майонез




Өй шартларында майонез ничек ясарга? Бер аш кашыгы горчица, 10 грамм шикәр комы, шул кадәр үк тоз алыгыз. Бергә кушып болгатыгыз. Икенче савытка бер йомырка сарысы, чирек кашык үсемлек мае салып, шуларны җылытып, әкрен генә горчица салыгыз. Болгатыгыз. Масса куе булырга тиеш. Аз гына аш серкәсе өстәргә дә мөмкин.




## Милиция өчен яңа бина

Район эчке эшләр бүлегенең яңа бинасы Киекле юлындагы яңа ягулык белән тәэмин итү станциясе каршында булачак.

Бинага нигез салынды инде. Төзелешне «53 нче СМУ» ОООсы алып бара. Биредә эчке эшләр бүлегенең барлык хезмәтләре да урнашачак. Шунда ук ярдәмче биналар да төзеләчәк.

## Нефтьчеләр «Кодак» ясый

«Норлатнефть» НГДУның биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлау цехында «Кодак» төсле фоторәсемнәр ясау цехы ачылды.

Цех әле яңа гына эшли башласа да, шәһәрдә аның абруе зур инде. Ни өчен дигәндә, «Кодак» фоторәсемнәрен ясату өчен пленканы шәһәр читендәге цехка илтеп йөрисе түгел, аны нефтьчеләр ОРСының теләсә нинди кибете кабул итеп ала. Фоторәсемнәр бер тәүлек эчендә әзер була. Иң мөһиме, аларның сыйфаты яхшы, бәяләре исә - шәһәрдә иң арзаны.

## Белдерүләр

### Сатабыз

**Советская ур., 187 - 32 адресында 1 бүлмәле фатир.**

***

**Чанада гараж.** Тел.: 5 - 25 - 76.

***

**9 х 4,5 метрлы йорт янкормасы, 10 данә ПК - 63 - 1,50 түбә плитәсе.** Победа ур., 12. Тел.: 5 - 10 - 79.

***

**Гараж өчен чана.** Школьная ур., 14 - 1.

***

**3 млн. сумга ГАЗ - 53 машинасы, 4 млн.га яңа «Урал» мотоциклы.** Тел.: 5 - 18 - 35, 19 сәг.тән соң.

***

**6 х 4 метрлы чанада гараж.** Тел.: 5 - 12 - 47.

***

**Йорт.** Энгельс ур., 11. Тел.: 2 - 10 - 97 (7дән 16 сәг.кә кадәр).

***

**«Урал» мотоциклы 3600 км. юл үткән, бәясе килешү буенча.** Тел.: 5 - 25 - 86.

***

**Декабристлар урамында 56 йорт.**

***

**1989 елгы ВАЗ - 21093 автомашинасы, 1500 двигателе, КПП - 5, люк, фаркоп.** 17 сәг. соң Школьная ур., 92 йортка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Норлат сәүдә базасында түмәрләп һәм ваклап төзелеш материаллары: цемент - тоннасы 520 мең, рубероид - 64 мең, шифер - 19 мең, цинкланган профлист - кв. метры 64 мең, «Рабица» сеткасы - 10 метры 160 мең, кадаклар - мебель өчен - төргәге (200 гр.) - 5100, шифер өчен - кг. 10 мең, төзелеш өчен кг.мы 8 мең, олиф - кг. мы 13 мең, ассортиментта буяулар.**

**Продуктлар: тавык ботлары - кг.мы 11100 сум, банан, алма, лимон, апельсин - 5500 сум, 1,5 литрлы «Лагуна» минераль суы - 3500 сум, «Рамено» - 3600 сум, 1,5 литрлы эчемлекләр: кура җиләге, апельсин суы, «Тоник» - 3650 сум.**

### Төрлесеннән

**«Мелиорация» Октябрь ПМКсы (127 нче ПМК) АҖсенә даими эшкә электр белән эретеп ябыштыручылар кирәк. Түләү - эш башыннан.**

### «Татнефть» АҖсе акционерлары игътибарына!

**«Татнефть» коммандит ширкәте, «Солид һәм компания» «Татнефть» АҖсенең «А» категориядәге акцияләрен сатып ала, бәясе 50000 сум.**

«Норлатнефть» НГДУсына мөрәҗәгать итәргә, тел.: 65 - 3 - 13.

***

**«АК БАРС» Банкының Норлат вәкиллеге «Татинфрабанк» вексельләрен ала.** Норлат шәһәрендә Советская ур., 144 адресына мөрәҗәгать итәргә, тел.: 5 - 13 - 85.

***

**Кошки авылында район шифаханәсе каршында СТО ачылды. Хезмәт күрсәтү һәм ремонтның барлык төрләре бар. 1996 елгы ВАЗ - 21083 машинасы сатыла.**

Администрация.

***

**Район эчке эшләр бүлеге каршында сак бүлегенә электромонтерлар кирәк. Белгечлеге булмаган очракта укыту мөмкинлеге бар.**

Администрация.

***

Югары Норлат урта мәктәбе тарафыннан 1996 нчы елда Шәфиев Илназ Юныс улы исеменә бирелгән А 0027273 номерлы аттестатны гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

Әхмәтвәлиев Илсөяр Хөсәенович исеменә документлар белән сумка табучының Мичурин ур., 12 йортка иясенә кайтаруын сорыйбыз (бүләк бәрабәренә).

### Алмаштырабыз

**Йорт һәм бер бүлмәле фатир ике яки өч бүлмәле фатирга.** Тел.: 5 - 13 - 40 (17 сәг.тән 19 сәг.кә кадәр).

***

**Полевая урамында йорт бер бүлмәле фатирга.** Тел.: 5 - 13 - 40 (17 сәг.тән 19 сәг.кә кадәр).



### *Очрашуга чакырабыз*

***1 нче мәктәпне 1987 елда тәмамлаучыларның очрашуы 1997 елның 14 июнендә 15 сәг.тә була.***

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7194